МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.09.2019 Казан ш. № 721

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 23.89 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 9.13 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне (социаль хезмәт күрсәтү объектларының һәм социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәүдән читләшү өлешендә):

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры;

министр урынбасары (дәүләт контроленең тиешле өлкәсенә кураторлык итүче) карап тикшерә дип билгеләргә.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Э.Ә. Зарипова